КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 29 гыйнвар г.Казань № 36

Инновацион эшчәнлек турында килешү төзү һәм югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар резидентлары реестрына кертү тәртибен раслау хакында

«Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» 2009 елның 17 июнендәге 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Инновацион эшчәнлек турында килешү төзү һәм югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар резидентлары реестрына кертү тәртибен расларга.

2. Бу карарның гамәле 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021ел, 29 гыйнвар, 36 нчы
карары белән расланды

## Инновацион эшчәнлек турында килешү төзү һәм югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар резидентлары реестрына кертү тәртибе

### I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип инновацион эшчәнлек турында килешү (алга таба – Килешү) төзү, аңа үзгәреш кертү һәм аны өзү механизмын һәм югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар резидентлары реестрына (алга таба – Резидентлар реестры) кертү механизмын билгели.

1.2. Әлеге Тәртиптә файдаланыла торган төшенчәләр һәм терминнар «Фән һәм дәүләт фәнни-техник сәясәте турында» 1996 елның 23 августындагы 127-ФЗ номерлы Федераль законда, «Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» 2009 елның 17 июнендәге 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында килә торган мәгънәләрдә кулланыла. Әлеге Тәртип максатларында кулланыла торган башка төшенчәләр һәм терминнар түбәндәге мәгънәдә файдаланыла:

Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк – «Югары технологияләр өлкәсендәге «ИТ-парк» технопаркы» дәүләт автоном учреждениесе;

заявка бирүче – Килешү төзү һәм Резидентлар реестрына кертү өчен заявка биргән хуҗалык җәмгыяте йә индивидуаль эшмәкәр;

проект – мәгълүмат технологияләре өлкәсендә инновацион карарлар булдыру буенча, шул исәптән фәнни һәм (яки) фәнни-техник нәтиҗәләрне коммерцияләштерү буенча икътисадый нәтиҗәгә ирешүгә юнәлдерелгән чаралар комплексы;

продукт – яңа товар, хезмәт күрсәтү, җитештерү (технология) ысулы яки башка иҗтимагый файдалы нәтиҗә рәвешендә практик яктан гамәлгә ашырылган инновацион эшчәнлек (яңалык кертү, инновация) нәтиҗәсе;

экспертлар советы – Килешү төзү һәм Резидентлар реестрына кертү өчен заявка бирүчеләрнең эшчәнлеген әлеге Тәртип белән билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен һәрьяклап һәм объектив карап тикшерү һәм бәяләү максатларында Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк тарафыннан төзелә торган киңәшмә орган;

«үтәли» цифрлы технологияләр – ясалма интеллект, яңа җитештерү технологияләре, робототехника һәм сенсорика, интернет әйберләр, бишенче буынның мобиль элемтә челтәрләре (цифрлы сервислар), яңа коммуникация интернет-технологияләре, виртуаль һәм тулыландырылган чынбарлык технологияләре, бүленгән реестрлар технологияләре, квантлы коммуникацияләр, квантлы сенсорлар, квантлы исәпләүләр кебек югары технологияле өлкәләрне үстерүгә аеруча зур йогынты ясый торган төп фәнни-техник юнәлешләр.

## II. Заявка бирүчеләргә карата таләпләр

2.1. Заявка бирүче, түбәндәге шартлар бер үк вакытта үтәлгәндә, Килешү төзүгә һәм Резидентлар реестрына кертүгә дәгъва итәргә хокуклы:

хисап (салым) чорында керемнең кимендә 90 проценты Гомумроссия икътисадый эшчәнлек төрләре классификаторының 62 нче «Әлеге өлкәдә компьютер программа тәэминатын эшләү, консультация хезмәтләре һәм башка иярчен хезмәтләр күрсәтү» һәм 63 нче «Мәгълүмат технологияләре өлкәсендә эшчәнлек» кодларына туры килә торган икътисадый эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашырудан кергән керем тәшкил итү;

Татарстан Республикасы территориясендә теркәлү һәм эшчәнлекне гамәлгә ашыру;

мәгълүмат технологияләре өлкәсендә, шул исәптән «үтәли» цифрлы технологияләр өлкәсендә проект һәм (яки) продукт булу.

## III. Заявка бирүгә карата таләпләр

3.1. Килешү төзү һәм Резидентлар реестрына язылу өчен заявка бирүче тарафыннан бу Тәртип кушымтасындагы форма нигезендә, әлеге Тәртип таләпләренә таянып, рәсмиләштерелгән заявка бирелә.

3.2. Заявка Югары технологияләр өлкәсендәге технопаркның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла торган электрон документлар рәвешендә тапшырыла.

## IV. Заявка составындагы документлар исемлеге

4.1. Заявка түбәндәге документларны үз эченә ала:

а) рус телендә электрон рәвештә язылган анкета, анда түбәндәге мәгълүматлар бирелә:

юридик затның яки индивидуаль эшмәкәрнең төп дәүләт теркәү номеры;

салым түләүченең (юридик зат яки индивидуаль эшмәкәрнең) тәңгәлләштерү номеры;

юридик затның оештыру-хокук формасы;

хуҗалык җәмгыятенең исеме яки индивидуаль эшмәкәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда);

юридик затның урнашу урыны яки индивидуаль эшмәкәрнең Россия Федерациясендә яшәү (тору) урыны;

Гомумроссия икътисадый эшчәнлек төрләре классификаторының 62 нче «Әлеге өлкәдә компьютер программа тәэминатын эшләү, консультация хезмәтләре һәм башка иярчен хезмәтләр күрсәтү» һәм 63 нче «Мәгълүмат технологияләре өлкәсендә эшчәнлек» кодларына туры килә торган икътисадый эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашырудан кергән керем күләме (өлеше);

хуҗалык җәмгыяте җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда);

элемтәгә керү өчен мәгълүмат (телефон, электрон почта адресы, рәсми сайт

(соңгысы – булганда));

проект һәм (яки) продукт турында мәгълүматлар;

гариза бирүче һәм Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк арасында элек төзелгән Килешүләр, дәүләт мөлкәтен арендалау шартнамәләре, торак булмаган урынны арендалау шартнамәләре, бизнес-инкубацияләү хезмәтләре күрсәтү турындагы шартнамәләр турында мәгълүматлар (булганда);

б) заявка бирүченең мәнфәгатьләрен кайгыртуга ышанычнамәнең электрон (сканерланган) күчермәсе, әгәр дә ул заявка бирүче вәкиле тарафыннан тапшырылса;

в) Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк белән элек төзегән электрон (сканерланган) Килешү, шулай ук дәүләт мөлкәтен арендалау шартнамәсе, торак булмаган урынны субарендалау шартнамәсе, бизнес-инкубацияләү хезмәтләре күрсәтү турында шартнамә (булганда).

## V. Заявкалар кабул итү һәм аларны карап тикшерү

5.1. Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк заявкалар кабул итүне һәм аларны аена кимендә бер тапкыр карап тикшерүне гамәлгә ашыра.

5.2. Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк ай саен, айның бишенә кадәр, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында заявкаларны кабул итү һәм карап тикшерү вакытлары турында мәгълүмат урнаштыра.

5.3. Югары технологияләр өлкәсендәге технопаркка әлеге Тәртипнең 5.2 пункты нигезендә билгеләнә торган заявкаларны кабул итү һәм карап тикшерү вакыты узганнан соң кергән мәгълүмат һәм документлар (Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк тарафыннан заявка бирүчедән соратып алынган мәгълүмат һәм документлардан тыш) исәпкә алынмый һәм карап тикшерелми.

5.4. Заявка кергәндә Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк заявканы теркәүгә ала һәм аңа номер бирә.

5.5. Заявкаларны карап тикшергәндә, Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

гаризаны карап тикшерүгә кабул итү турында;

гаризаны карап тикшерүдән баш тарту турында.

5.6. Заявканы карап тикшерүдән баш тарту турындагы карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

а) заявка бирүче әлеге Тәртип белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәгәндә;

б) заявка бирүче әлеге Тәртипнең 4.1 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәгәндә;

5.7. Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк заявканы карап тикшерүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көннән ике эш көне эчендә заявка бирүчегә аның турында, гаризаны карап тикшерүдән баш тарту сәбәбен нигезләп, электрон почта аша хәбәр итә.

5.8. Заявка бирүче заявканы карап тикшерүдән баш тарту турында хәбәрнамә алган очракта, заявка бирүче заявкаларны кабул итү һәм карап тикшерү вакыты чыкканга кадәр Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк тарафыннан заявканың бу Тәртип таләпләренә карата ачыкланган туры килмәүләрен бетерү максаты белән заявкага үзгәрешләр кертергә хокуклы.

5.9. Цензурасыз яки кимсетү сүзләре, бер-берсенә бәйле булмаган символлар җыелмасы, законнар таләпләрен боза торган эшчәнлекне гамәлгә ашыруга чакырулар булган заявка теркәлми.

5.10. Заявканы карап тикшерү йомгаклары буенча Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) Килешүгә имза кую һәм Резидентлар реестрына кертү турында, әгәр дә Заявка бирүче тарафыннан заявка составында әлеге Тәртипнең 4.1 пунктындагы «г» пунктчасында күрсәтелгән документлар тапшырылган булса;

б) әлеге Тәртипнең 4.1 пунктындагы г» пунктчасында күрсәтелгән документлар булмаган очракта, карап тикшерү өчен экспертлар советына заявка җибәрү турында.

Заявка эксперт советына карап тикшерүгә җибәрелгән очракта, Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк әлеге карар кабул ителгән көннән ике эш көне эчендә бу турыда гариза бирүчегә электрон почта аша хәбәр итә.

Әгәр дә заявкада әлеге Тәртипнең 4.1 пунктындагы «а» – «г» пунктчаларында каралган документлар булса, Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк заявканы теркәгән көннән биш эш көне эчендә заявка бирүче белән электрон рәвештә Килешү төзи һәм заявка бирүчене Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк резиденты буларак Резидентлар рееестрына теркәү турында язма (алга таба – реестр язмасы) язып куя.

5.11. Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк заявка бирүченең әлеге Тәртипнең 2.1 пунктындагы бишенче абзацында билгеләнгән шартларга туры килү-килмүвен бәяләү өчен экспертлар советы төзи.

5.12. Экспертлар советының эш тәртибе, әлеге Тәртипнең таләпләрен исәпкә алып, Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк тарафыннан раслана торган экспертлар советы турындагы нигезләмәгә таянып билгеләнә.

5.13. Экспертлар советы составы Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк тарафыннан раслана.

5.14. Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк экспертлар советының утырышын үткәрү датасы һәм вакыты турындагы мәгълүматны Югары технологияләр өлкәсендәге технопаркның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында утырыш үткәрү көненә кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча бастырып чыгара. Утырышлар көндезге формада яки читтән торып үткәрелә.

5.15. Заявканы бәяләү нәтиҗәләре буенча экспертлар советы түбәндәге карарларны чыгара:

заявка бирүче белән Килешү төзү һәм аны Резидентлар реестрына кертү турында;

Заявка бирүче белән Килешү төзүдән баш тарту турында.

5.16. Эксперт советы карарлары заявкаларны карап тикшерүгә йомгаклар ясау буенча экспертлар советы утырышы беркетмәсе (алга таба – Беркетмә) рәсмиләштерелә. Беркетмәне экспертлар советы секретаре алып бара. Беркетмә экспертлар советы рәисе тарафыннан экспертлар советы утырышын үткәргән көннән өч эш көне эчендә раслана.

5.17. Заявкаларны карап тикшерү йомгаклары турында мәгълүматлар (Экспертлар советының беркетмәсен раслау датасы турындагы мәгълүматны кертеп) Югары технологияләр өлкәсендәге технопаркның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла һәм заявка бирүчегә Беркетмә расланган көннән өч эш көне эчендә җибәрелә.

5.18. Заявканы карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Килешү төзүдән баш тартылган заявка бирүче яңа заявка белән билгеләнгән тәртиптә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

5.19. Экспертлар советы тарафыннан аларны резидентлар итеп билгеләү турында карар кабул ителгән заявка бирүчеләр Беркетмә расланган көннән 10 эш көне эчендә Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк белән электрон рәвештә Килешү төзи.

Заявка бирүче тарафыннан әлеге срок бозылган очракта, резидент белән Килешү төзү турындагы карар гамәлдән чыгарылган дип санала.

## VI. Килешү төзү һәм аны өзү

6.1. Заявка бирүче Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк белән билгеләнгән тәртиптә Килешү төзелгән һәм Резидентлар реестрына реестр язмасы язылган вакыттан Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк резиденты дип танала. Реестр язмасы Резидентлар реестрына Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк тарафыннан Килешү төзелгән көннән биш эш көне эчендә языла.

Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк резидентка реестр язмасын Резидентлар реестрына язу турындагы мәгълүматны Резидентлар реестрына реестр язмасы язылган көннән бер эш көне эчендә электрон почта аша хәбәр итә.

Реестр язмасында түбәндәге мәгълүматлар бирелә:

а) язылу номеры;

б) Резидентлар реестрына язып кую датасы;

в) оешманың яки индивидуаль эшмәкәрнең тулы исеме;

г) төп дәүләт теркәү номеры;

д) салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры;

е) Килешүнең датасы һәм номеры;

ж) Резидентлар реестрындагы мәгълүматларга кертелгән үзгәрешләр турында мәгълүматлар (булган очракта);

з) резидент тарафыннан гамәлгә ашырыла торган эшчәнлек төрләре турында мәгълүматлар;

и) үтәли цифрлы технологияләр өлкәсендә проект һәм (яки) продукт турында мәгълүматлар.

6.2. Килешү иң күбе өч елга төзелә.

6.3. Резидентлар реестры Югары технологияләр өлкәсендәге технопаркның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында электрон рәвештә алып барыла. Резидентлар реестрын алып бару тәртибе Югары технологияләр өлкәсендәге технопаркның локаль норматив акты белән билгеләнә.

6.4. Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк тарафыннан Килешүне өзү түбәндәге очракларда гамәлгә ашырыла:

а) Резидентлар реестрына кертелгән резидентның әлеге Тәртип белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве ачыкланганда;

б) Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына резидентның (юридик затның)

бетерү процессында булуы яисә индивидуаль эшмәкәрнең үз эшчәнлеген туктатуы турында язылганда;

в) кушылу, бүленү, кушу, бүлеп чыгарылу яки үзгәртеп оештырылу рәвешендә үзгәртеп оештыру нәтиҗәсендә резидентның эшчәнлеге туктатылганда;

г) резидентны банкрот дип тану турындагы суд карары законлы көчкә кергәндә;

д) резидент тарафыннан Килешү шартлары үтәлмәгәндә;

е) резидент инициативасы буенча;

ж) Килешү, дәүләт мөлкәтен арендалау шартнамәсе, торак булмаган урынны субарендалау шартнамәсе, бизнес-инкубацияләү хезмәтләре күрсәтү турындагы шартнамә нигезендә Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк соравы буенча резидент тарафыннан соратыла торган мәгълүмат тапшырылмаганда;

з) дәүләт мөлкәтен арендалау шартнамәсе, торак булмаган урынны субарендалау шартнамәсе, бизнес-инкубацияләү хезмәтләре күрсәтү турындагы шартнамә өзелгәндә.

6.5. Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк Килешүне өзү турында карар кабул ителгән көннән 10 эш көне эчендә әлеге мәгълүматны Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә һәм Килешүне өзү турында карар кабул ителгән резидентка җибәрә, шулай ук Резидентлар реестрына тиешле үзгәрешләр кертә.

6.6. Әлеге Тәртипнең 6.4 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча Килешүне өзү турындагы карар кабул ителгән резидент әлеге карарга карата Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять бирергә хокуклы.

Инновацион эшчәнлек турында килешү төзү һәм югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар резидентлары реестрына кертү тәртибенә
кушымта

Форма

Инновацион эшчәнлек турында килешү

Казан/Яр Чаллы шәһәре _______ ел, «__» _________________

«Югары технологияләр өлкәсендәге «ИТ-парк» технопаркы» дәүләт автоном учреждениесе (алга таба – Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк) _________________________________________________________________ йөзендә,
(вазыйфасы һәм Ф.И.Ат.ис. )
______________________________________________________________ нигезендә эш итүче, бер яктан, һәм ____________________________________________________,
(оешманың/индивидуаль эшмәкәрнең исеме һәм оештыру-хокук формасы)
_________________________________________________________________ йөзендә,
(вазыйфасы һәм Ф.И.Ат.ис./шәхси эшмәкәр өчен Ф.И.Ат.ис.)
_____________________________________________________________ нигезендә эш итүче
(затның имза куюга вәкаләтен таныклый торган документ йә индивидуаль эшмәкәрнең төп дәүләт теркәү номеры таныклыгы)
(алга таба – Резидент), икенче яктан, алга таба Яклар дип аталган, түбәндәгеләр турында бу Килешүне (алга таба – Килешү) төзеделәр:

## 1. Килешү предметы

1.1. Резидент Гомумроссия икътисадый эшчәнлек төрләре классификаторының 62 нче «Әлеге өлкәдә компьютер программа тәэминатын эшләү, консультация хезмәтләре һәм башка иярчен хезмәтләр күрсәтү» һәм 63 нче «Мәгълүмат технологияләре өлкәсендә эшчәнлек» кодларына туры килә торган ________________________________________ икътисадый эшчәнлек төрләре буенча Килешү белән күздә тотылган шартларда Килешү төзү өчен биргән заявка нигезендә инновацион эшчәнлекне башкарырга бурычлы.

## 2. Якларның хокуклары һәм бурычлары

2.1. Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк түбәндәгеләргә бурычлы:

төбәктә инновацион бергәлекне һәм технологик эшмәкәрлекне үстерүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашырырга;

резидентны югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар резидентлары

реестрына (алга таба – Резидентлар реестрына) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Инновацион эшчәнлек турында килешү төзү һәм югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар резидентлары реестрына кертү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 29 гыйнвар, 36 нчы карары белән расланган Инновацион эшчәнлек турында килешү төзү һәм югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар резидентлары реестрына кертү тәртибе (алга таба – Тәртип) нигезендә кертергә;

Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк тарафыннан Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк резидентларына ярдәм күрсәтү программаларында катнашу, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган инновацион эшчәнлеккә ярдәм күрсәтү программаларында катнашу мөмкинлеге турында хәбәр итүне гамәлгә ашырырга;

резидентларның продуктларын, товарларын һәм хезмәт күрсәтүләрен эчке һәм тышкы базарларга чыгаруда булышлык күрсәтүне гамәлгә ашырырга;

резидент тарафыннан әлеге Килешүнең үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашырырга;

резиденттан Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк белән идарә итү функциясен башкару буенча үз вәкаләтләре кысаларында эшчәнлекнең финанс-икътисадый күрсәткечләрен электрон почта аша соратып алырга;

резидент тарафыннан бирелгән реклама-мәгълүмат материалларын Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк товарлары һәм хезмәт күрсәтүләре маркетингы чараларын гамәлгә ашыру өчен файдаланырга.

2.2. Резидент түбәндәгеләргә бурычлы:

Югары технологияләр өлкәсендәге технопаркта әлеге Килешүнең 1.1 пунктында каралган инновацион эшчәнлек алып барырга;

Тәртип белән билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен тәэмин итәргә;

рәсми сорау кергәндә, Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк белән мәгълүмати хезмәттәшлекне гамәлгә ашырырга, компания, компаниянең товарлары һәм хезмәт күрсәтүләре турындагы мәгълүматны, шулай ук хисап мәгълүматларын (финанс-икътисадый күрсәткечләрне кертеп) һәм башка мәгълүматларны җаваплы хезмәткәрнең электрон адресына йә кәгазьдә хат итеп җибәрү юлы белән мөстәкыйль рәвештә кертергә һәм актуальләштерергә;

Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк эшчәнлегенә кагылышлы рекламаны һәм башка мәгълүматларны Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк белән язма рәвештә килештермичә таратмаска;

үз логотибын, товар билгесен, фирма атамасын Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк сайтында, тарату материалларында, презентация буклетларында һәм брошюраларында кулланырга ризалык бирергә.

2.3. Резидент әлеге Килешү буенча үз хокукларын һәм бурычларын башка затка тапшырырга хокуклы түгел.

## 3. Килешүгә үзгәреш кертү һәм аны өзү шартлары. Килешүнең гамәлдә булу вакыты

3.1. Әлеге Килешү аңа кул куйган көннән үз көченә керә һәм ___________________________ кадәр гамәлдә була.

3.2. Әлеге Килешүгә Якларның язма ризалыгы белән үзгәреш кертелергә мөмкин.

3.3. Әлеге Килешүнең гамәле түбәндәге очракларда туктатыла:

Резидентлар реестрына кертелгән резидентның Тәртип таләпләренә туры килмәве ачыкланганда;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына резидентның (юридик затның) бетерү процессында булуы яисә индивидуаль эшмәкәрнең үз эшчәнлеген туктатуы турында язу язылганда;

кушылу, бүленү, кушу, бүлеп чыгарылу яки үзгәртеп оештырылу рәвешендә үзгәртеп оештыру нәтиҗәсендә резидентның эшчәнлеге туктатылганда;

резидентны банкрот дип тану турындагы суд карары законлы көчкә кергәндә;

резиденты тарафыннан Килешү шартлары үтәлмәгәндә;

резидент инициативасы буенча;

Килешү, дәүләт мөлкәтен арендалау шартнамәсе, торак булмаган урынны субарендалау шартнамәсе, бизнес-инкубацияләү хезмәтләре күрсәтү турындагы шартнамә нигезендә Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк соравы буенча резидент тарафыннан соратыла торган мәгълүмат тапшырылмаганда;

дәүләт мөлкәтен арендалау шартнамәсе, торак булмаган урынны субарендалау шартнамәсе, бизнес-инкубацияләү хезмәтләре күрсәтү турындагы килешү өзелгәндә.

## 4. Хезмәттәшлек шартлары һәм принциплары

4.1. Яклар хезмәттәшлекне тигез хокуклылык, бер-берсенең оператив эшчәнлегенә кысылмау һәм законлылык принциплары нигезендә гамәлгә ашыра.

4.2. Хезмәттәшлекне гамәлгә ашырганда, Яклар максатка ярашлылык һәм икътисадый нәтиҗәлелек принципларыннан чыгып эш итә.

4.3. Яклар әлеге Килешү белән җайга салына торган мөнәсәбәтләрне һәм ниятләрне үстерүгә карата башка килешүләр яки хуҗалык шартнамәләре төзергә мөмкин.

4.4. Яклар әлеге Килешү кысаларында алынган конфиденциаль мәгълүматны таратмау турындагы шартнамәне үтәүгә гарантия бирә.

4.5. Мәгълүматны өченче затларга тапшыру бу мәгълүматны биргән Якларның язма ризалыгы белән гамәлгә ашырыла.

## 5. Йомгаклау нигезләмәләре

5.1. Әлеге Килешү бер үк юридик көчкә ия ике нөсхәдә, Якларның һәркайсы өчен берәр нөсхәдә төзелде.

5.2. Әлеге Килешүгә түбәндәгеләр теркәлә һәм аның аерылгысыз бер өлеше булып тора ___________________________________________________________.

(мәсәлән, кушымта, беркетмә, заявка, бизнес-план)

## 6. Якларның адресы, реквизитлары һәм имзалары:

| Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк | Резидент |
| --- | --- |
| ____________________ | _____________________________ |
| Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (ИНН) | Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (ИНН) |
| адресы __________________________ | адресы __________________________ |
| исәп-хисап счеты___________________ | исәп-хисап счеты___________________ |
| корреспондент счеты___________ | корреспондент счеты___________ |
| Банк _____________________________ | Банк _____________________________ |
| БИК ___________________ | БИК ___________________ |
| ______________ (имзасы) М.У. | ___________ (имзасы) М.У. (булганда) |

__________________________________